ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

# П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

9 октябрь 2015 ел № 844

2015 елда Нурлат муниципаль районында котыру авыруын профилактикалау чараларын көчәйтү турында

Хайваннарның котыру авыруы буенча эпизоотик хәлне яхшырту, шулай ук Нурлат муниципаль районында котыру авыруын профилактикалау һәм әлеге авыруны авыру хайваннан кешегә күчерүгә юл куймау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат шәһәре һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә:

- караучысыз хайваннарны тоту эшен оештыру;торак пунктларда, - фермаларда, көтүләрдә этләр һәм мәчеләрнең күчмә тормышына юл куймау;
- үлгән һәм юк ителгән терлекләрнең мәетләрен бары тик үләт базларына илтеп утильләштерергә.

2. Районара хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм көйләү бүлегенең баш белгече Р. С. Мостафинга, Нурлат муниципаль районы аучылар һәм балыкчылар җәмгыяте рәисе О. Ф. Артемьевка:

- аучылык хуҗалыкларында төлкеләр санын чикләү буенча чаралар күрергә;
- котыру авыруы аркасында төлке аулау сезонын озайтырга;
- дәүләт хезмәтенә кирәк булганда кыргый хайваннарның үлеме яки гадәти булмаган тәртибе турында хәбәр итәргә;
-хайваннарны авыз иммунизациясе вакцинасын урнаштыруда ярдәм күрсәтергә һәм катнашырга;
-котыру авыруына каршы прививка ясатмаган кешеләрне һәм ау этләрен ауга кертмәскә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин